ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423958 Ютазы районы,
Акбаш авылы, Гоголь урамы, 1
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423958 Ютазинский район
село Акбаш ул. Гоголя, д.1
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№2 20.01.2015 ел.

Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2014 елның 23 октябрендәге
"Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
Административ регламентларын
раслау турында"гы 11 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 31 декабреннән «Россия Федерациясе чикләрендә йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү турында»28.12.2013 ел, № 387 –ФЗ Федераль законның 2 статьясы үз көченә керү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең һәм Ютазы районы прокурорының 02-08-01-2015 санлы протестының үз көчләрен югалтуын тану турындагы нигезләмәсе сәбәпле,

1. Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 23 октябрендәге "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында"гы 11 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
   - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетында белешмә(өземтә) бирү буенча хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасына муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының 2.5 пунктын " Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге «кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Яшәү урыныннан белешмә алу өчен, өйгә китаплардан Өземтә, яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

1.1. Шәхесне раслаучы документлар.
1.2. Йорт китабы.
1.3. Шәхси торак йортка хокуклар турында документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык йә индивидуаль торак йортка техник (кадастр) паспорты, йә Ростехинвентаризациядән хокук ияләре турында белешмә- Федераль БТИ, Татарстан Республикасы филиалы).

2.Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

2.1. Шәхесне раслаучы документлар.
2.2. Йорт китабы.
2.3. Соратып алына торган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык).

3.Үлүченең яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

3.1. Шәхесне раслаучы документ.
3.2. Йорт китабы.
3.3. Үлем турында таныклык (оригинал).
3.4. Соратып алына торган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык).

4.Хуҗалык кенәгәсеннән өземтә алу өчен тәкъдим итәргә кирәк:

4.1.хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү турында ирекле формада гариза;
4.2. Хокук иясенең шәхесен таныклаучы документ;
4.3.җир участогы хуҗасының вафат булуы турында таныклык күчермәсе;
4.4.җир кишәрлегендә урнашкан йортка (башка объектлар булса) хокук билгели торган документлар күчермәләре;
4.5. җир кишәрлегендә урнашкан йортның адрес саны күрсәтелгән фотосүрәте.

5.Физик зат вәкиле өчен мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен затның вәкаләтләрен раслаучы нотариаль расланган документ күчермәсен тапшырырга кирәк.

6.Санап үтелгән документлар тиешле документларның оригиналлары белән бергә тапшырыла.

7.Гаризалар, документлар һәм документларның күчермәләре бер нөсхәдә тапшырыла.»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендында һәм Интернет челтәрендәһәм түбәндәге адрес буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: www.yutaza.tatar.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Акбаш авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе И.М.Миңнеханов

исп.Ахметова Ф.Р. 4-14-34